# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**от 27.10.2022** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 27 октяберендә 13 сәгать 00 минутта, 2022 елның 27 октяберендә 14 сәгать 30 минутта этаплап уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1).Кадыбаш авылында скважиналар өчен тирәнлек насослары сатып алу һәм ремонтлау, суүткәргеч челтәрен ремонтлау ;санитар саклау зонасы проектын эшләү,җир асты байлыклары участоклары буенча гидрогеологик бәяләмә алу, Кадыбаш бистәсендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналары проектлары буенча санитар – эпидемиологик нәтиҗә алу, башка агымдагы чыгымнарны түләү;

2)Кадыбаш авылындагы урамнарны яктырту чаралары (урам яктырткычларын,электр товарларын сатып алу, урнаштыру, алмаштыру һәм хезмәт шартнамәсе буенча электрикка түләү); һәм башка эшләр;

3) Кадыбаш авылындагы урамнарны кардан чистарту (юлларга хезмәт күрсәтү, үлән чабу, кардан чистарту, дизель ягулыгы, дизель мае, Кадыбаш авылындагы трактор өчен ягулык-май сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү) һәм территорияне төзекләндерү буенча башка эшләр;

4)Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм хезмәт шартнамәсе буенча янгын сүндерү

машинасы йөртүчесенә түләү, янгын сүндерү машинасына бензин сатып алу, запас частьлар сатып алу ) һәм башка эшләр;

5) Кадыбаш авылында Гали урамына,Яшьләр урамына,Тау асты урамына юл салу һәм җәю өчен вак таш сатып алу һәм башка агымдагы чыгымнар;

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 266 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 140 кеше, бу 52,6 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 140 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1).Кадыбаш авылында скважиналар өчен тирәнлек насослары сатып алу һәм ремонтлау, сусүткәргеч челтәрен ремонтлау ;санитар саклау зонасы проектын эшләү,җир асты байлыклары участоклары буенча гидрогеологик бәяләмә алу, Кадыбаш бистәсендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналары проектлары буенча санитар – эпидемиологик нәтиҗә алу, башка агымдагы чыгымнарны түләү;

2)Кадыбаш авылындагы урамнарны яктырту чаралары (урам яктырткычларын,электр товарларын сатып алу, урнаштыру, алмаштыру һәм хезмәт шартнамәсе буенча электрикка түләү); һәм башка эшләр;

3) Кадыбаш авылындагы урамнарны кардан чистарту (юлларга хезмәт күрсәтү, үлән чабу, кардан чистарту, дизель ягулыгы, дизель мае, Кадыбаш авылындагы трактор өчен ягулык-май сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү) һәм территорияне төзекләндерү буенча башка эшләр;

4)Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм хезмәт шартнамәсе буенча янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә түләү, янгын сүндерү машинасына бензин сатып алу, запас частьлар сатып алу ) һәм башка эшләр;

5) 5.1 Кадыбаш авылында Гали урамына,Яшьләр урамына,Тау асты урамына юл салу өчен ком һәм вак таш сатып алу һәм башка агымдагы чыгымнар;

5.2 Күперне ремонтлау (Кадыбаш авылындагы чишмәгә бара торган күперне төзү өчен агач материаллары сатып алу);

6) Кадыбаш авылын төзекләндерү шул исәптән;

- куркыныч янаган агачларны, коры, яшел куакларны кисү (куакларны юк итү өчен гербидцидлар сатып алу һәм куакларны кисәр өчен бензин сатып алу);

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
авыл җирлеге Башлыгы Х.Л.ЗАКИРОВ